# КАРАР

**26 ноябрь, 2024 ел** **№1**

**Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге Югары Шөн авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 26 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:
«Сез 2025 елда Кукмара муниципаль районының Важашур авыл җирлеге Югары Шөн авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге 4 яисә аннан да күбрәк бала тәрбияләүче гаиләләрдән; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация һәм контракт буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту *(Югары Шөн авылында урам-юл челтәрен карап тоту, ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, проект-смета документлары, юлларны карап тоту буенча башка эш төрләре);*

*(юлларга вак таш салу, ремонтлау һәм төзекләндерү, вак таш сатып алу, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, юлларны төзү, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре);*

- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм аларга бирелгән мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау *(урам яктыртуны карап тоту, комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, урам яктырткычларын ремонтлау һәм сатып алу, Югары Шөн авылында урам яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре*);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (*спорт мәйданчыгын төзү, карап тоту, төзекләндерү, җиһазлау,инвентарь, җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, Югары Шөн авылы спорт мәйданчыгын төзү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре)*;

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү *(Югары Шөн авылында янгын гидрантлары, янгын краннары сатып алу һәм урнаштыру, янгынга каршы инвентарь сатып алу, проект-смета документлары)*;

- традицион күмү урыннарын төзекләндерү, койма кору, ремонтлау *(Югары Шөн авылында зират территориясен төзекләндерү һәм карап тоту, материал сатып алу һәм урнаштыру, коймаларны ремонтлау, инвентарь сатып алу, зират территориясен төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре; проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә*

*ашыру);*

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау *(су белән тәэмин итү челтәрләрен, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру, материаллар сатып алу, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, Югары Шөн авылында су белән тәэмин итүне, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту буенча башка эш төрләре)*;

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү *(Югары Шөн авылы чишмәләрен ремонтлау, карап тоту, төзекләндерү, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, чишмәләрне төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре);*

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 191 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 100 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 100 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлегенең Югары Шөн авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Сез 2025 елда Кукмара муниципаль районының Важашур авыл җирлеге Югары Шөн авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге 4 яисә аннан да күбрәк бала тәрбияләүче гаиләләрдән;
80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация һәм контракт буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту *(Югары Шөн авылында урам-юл челтәрен карап тоту, ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, проект-смета документлары, юлларны карап тоту буенча башка эш төрләре);*

*(юлларга вак таш салу, ремонтлау һәм төзекләндерү, вак таш сатып алу, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, юлларны төзү, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре);*

- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм аларга бирелгән мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элементләрен тәэмин итү һәм электр

энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау *(урам яктыртуны карап тоту, комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, урам яктырткычларын ремонтлау һәм сатып алу, Югары Шөн авылында урам яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре*);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (*спорт мәйданчыгын төзү, карап тоту, төзекләндерү, җиһазлау,инвентарь, җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, Югары Шөн авылы спорт мәйданчыгын төзү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре)*;

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү *(Югары Шөн авылында янгын гидрантлары, янгын краннары сатып алу һәм урнаштыру, янгынга каршы инвентарь сатып алу, проект-смета документлары)*;

- традицион күмү урыннарын төзекләндерү, койма кору, ремонтлау *(Югары Шөн авылында зират территориясен төзекләндерү һәм карап тоту, материал сатып алу һәм урнаштыру, коймаларны ремонтлау, инвентарь сатып алу, зират территориясен төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре; проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);*

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау *(су белән тәэмин итү челтәрләрен, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру, материаллар сатып алу, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, Югары Шөн авылында су белән тәэмин итүне, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту буенча башка эш төрләре)*;

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү *(Югары Шөн авылы чишмәләрен ремонтлау, карап тоту, төзекләндерү, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, чишмәләрне төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре);*

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип исәпләргә.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәсен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ruадресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Рәислек итүче
Важашур авыл җирлеге башлыгы П.Л. Иванов